Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.У. Әхмәтов,
О.М. Воронова,
А.И. Зыятдинов,
А.Н. Надршина,
А.С. Созинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Законы

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 75 (I өлеш); 2026, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 1 пунктындагы «в» пунктчасында «күрсәтү буенча (территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына кертелмәгән медицина ярдәме, шулай ук территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасында каралган медицина ярдәме өчен түләү тарифлары структурасына кертелмәгән чыгымнар өлешендә),» сүзләрен «(территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына кертелмәгән медицина ярдәме өлешендә, шулай ук территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасында каралган медицина ярдәме өчен түләү тарифлары структурасына кертелмәгән чыгымнар өлешендә), һава юлы суднолары белән гамәлгә ашырыла торган санитария-авиация эвакуациясе хезмәтләре күрсәтү буенча,» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлешнең икенче һәм өченче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) сәламәтлек саклау өлкәсендә аерым чараларны финанслау механизмын камилләштерү максатларында эшләнде.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү, шулай ук медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләре сатып алуны тәэмин итү чараларын финанслау федераль бюджеттан финанслашу чыгымнары өлешендә берканаллы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – ТММИФ) бюджетына бюджетара трансфертлар бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Федераль казначылык федераль акчалардан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру барышында югарыда күрсәтелгән максатларга акчалар тотуны дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырырга тәкъдим итте.

Моңа бәйле рәвештә закон проектында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү буенча чараларны финанслауга финанс чаралары бүлеп бирү, шулай ук медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләре сатып алуны тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә субсидияләр бирү юлы белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аша гамәлгә ашырыла дип билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проектында «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының (алга таба – ТР Законы) 25 статьясындагы 2 өлешенә үзгәреш кертү ТММИФ бюджетына бюджетара трансфертлар исемлегеннән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү һәм һава юлы суднолары белән гамәлгә ашырыла торган санитария-авиация эвакуациясе хезмәтләре күрсәтү очракларын төшереп калдыру өлешендә үзгәреш кертү һәм ТР Законының 25 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктына көчә торган үзгәреш кертү каралган.

Закон проекты 2 статьядан гыйбарәт. Закон проектының 2 статьясында законның 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүе билгеләнгән.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанс белән тәэмин итү турында» 2016 елның 31 декабрендәге 1089 нчы номерлы һәм «Медицина ярдәме (махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация эшләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 елның 19 апрелендәге 312 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.